**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2010 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-616 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-897 номерлы, 2011 елның 25 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-187 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-458 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1073 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 20 февралендәге ПУ-183 номерлы, 2015 елның 8 апрелендәге ПУ-378 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы ПУ-323 номерлы, 2016 елның 11 июнендәге ПУ-527 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге ПУ-904 номерлы, 2016 елның 3 декабрендәге ПУ-1062 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 9 февралендәге ПУ-112 номерлы, 2017 елның 5 апрелендәге ПУ-288 номерлы, 2017 елның 6 маендагы ПУ-366 номерлы һәм 2017 елның 10 июнендәге ПУ-496 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ф.Р. Волкованы, А.В. Леухинны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәге затларны кертергә:

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын – Татарстан Республикасы юстиция министрын;

Якушев Сергей Леонидовичны – Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары – штаб башлыгын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы Л.Ю. Глухованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы», аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 19 июль
№ ПУ-628